ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.08.2020 ел Баулы шәһәре №171

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге 108 номерлы карары белән расланган (2019 елның 24 июлендәге 218 номерлы, 2020 елның 24 гыйнварындагы 11 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге 108 номерлы карары белән расланган (2019 елның 24 июлендәге 218 номерлы, 2020 елның 24 гыйнварындагы 11 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле 1.6. һәм 1.7 пунктлар өстәргә:

«1.6. Әлеге Регламентның гамәлдә булуы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылмый.

1.7. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51нче статьясы 12нче өлешендә һәм 52нче статьясы 3.3 өлешендә каралган очракларда капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү этапларына карата бирелергә мөмкин.»;

2нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.8 пунктта икенче баганада түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә:

«5) 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) гариза һәм электрон документлар тапшыру.»;

2.9 пунктта икенче баганада беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып җир участогына яисә җир участогына урнашкан күчемсез милек объектына карата суд бәхәсе булу, шулай ук хокук саклау органнары тарафыннан күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларына хокукны теркәү өчен нигез булган документларның законлылыгын тикшерү тора.

Муниципаль хезмәт күрсәтү суд карары законлы көченә кергәнче йә документларны тикшерү тәмамланганчы туктатып торыла.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров